ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.01.2026 г.Заинск № 26

**2026 елга гражданнарны аз керемлеләр дип тану максатларында керемнең һәм мөлкәт хакының иң чик күрсәткечләрен раслау турында**

Гражданнарны аз керемлеләр дип тану һәм аларга муниципаль торак фондында социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү максатларында, «Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Россия Федерациясе Торак кодексының 49,51 статьяларына, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. 2026 елга гражданнарны аз керемлеләр дип тану максатларында гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге мөлкәт хакының иң чик күрсәткечләрен Кушымта нигезендә расларга.
2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 30 гыйнварындагы 46 номерлы «Гражданнарны аз керемлеләр дип тану максатларында керемнең һәм мөлкәт хакының иң чик күрсәткечләрен билгеләү турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Зәй муниципаль районының рәсми сайтында http://zainsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.
4. Уртак торак-көнкүреш комиссиясенең гражданнарны социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак урынга мохтаҗлар буларак таныганда кушымтада күрсәтелгән чик күрсәткечләрдән файдаланырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан мизгеленнән үз көченә керә.
6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э.Галеев**

С.А.Филюшина
Юрист

Кушымта
Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы
Башкарма комитеты карары белән расланды
29. 01. 2026 елдан № 26

**Гражданнарны аз керемлеләр дип тану максатларында гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге мөлкәт хакының иң чик күрсәткече**

| Гаилә әгъзалары саны | Гражданны аз керемле дип тану максатларында гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге мөлкәт хакы чиге (сум) | Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга килә торган уртача айлык җыелма керемнең иң чик күрсәткече күләме (сум) |
|---|---|---|
| 1 | 912600 | 25556,38 |
| 2 | 1825200 | 25556,38 |
| 3 | 2737800 | 25556,38 |
| 4 | 3650400 | 25556,38 |
| 5 | 4563000 | 25556,38 |
| 6 | 5475600 | 25556,38 |
| 7 | 6388200 | 25556,38 |
| 8 | 7300800 | 25556,38 |
| 9 | 8213400 | 25556,38 |
| 10 | 9126000 | 25556,38 |

Башкарма комитетның эшләр идарәчесе Е.А.Васильева